**СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 елның «16» маеннан № 34

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында**

Коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә муниципаль норматив хокукый актлар таләпләренә туры китерү максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы башлыгының «Хокук саклау һәм контроль-күзәтчелек органнарыннан керә торган реакция ясау актларының электрон-мәгълүмат реестры һәм аларны үтәү нәтиҗәсе турында» 2012 елның 19 декабрендәге 66 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3 п. 2 п/п «Л.В.Михеева» сүзләрен төшереп калдырырга;

- 3 п. «Л.В.Михеева» сүзләрен төшереп калдырырга;

- «Электрон - мәгълүмати реестр алып бару» II бүлеге 1 нче кушымтасының 4 пунктында «Яңа Чишмә муниципаль районы коррупциягә каршы көрәш комиссиясе» сүзләрен «Яңа Чишмә муниципаль районында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

- «Реакцияләү актлары белән эшләү тәртибе» III бүлеге 1 нче кушымтасының 1 пункты, 2 пункты, 3 пунктында 1 нче кушымтада «Хокук саклау һәм контроль-күзәтчелек органнарыннан килә торган реакция актлары турында мәгълүмат» сүзләрен «Хокук саклау һәм контроль-күзәтчелек органнарыннан килә торган реакция актларының электрон-мәгълүмат реестры» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының «Яңа Чишмә муниципаль районының җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре һәм аларга килүчеләр өчен коррупция куркынычы тудыра торган хәлләрдә үз-үзләрен тоту турында» 2013 елның 04 гыйнварындагы 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «Коррупциягә куркыныч тудыручы хәлләр килеп чыккан очракта, муниципаль органнарга килүчеләр өчен тәкъдимнәр» бүлегенең 1 нче кушымтасында «Яңа Чишмә муниципаль районы Советының оештыру бүлеге начальнигы Әхмәтҗанова Альбина Рафаэльевнага, Яңа Чишмә ав., Совет ур., 80, тел.: 2-22-32.» сүзләрен «Яңа Чишмә муниципаль районы башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесенә, Яңа Чишмә ав. Совет ур., 80, тел.: 2-22-49»;

- 1 нче кушымтаның «Коррупциягә куркыныч тудыручы хәлләр килеп чыккан очракта, муниципаль органнарга килүчеләр өчен рекомендация» бүлегенең 10 пунктында «Россия Эчке эшләр министрлыгының «Чирмешән» муниципальара бүлегенең «Яңа Чишмә» полиция бүлекчәсе» сүзләрен, «Россия Эчке эшләр министрлыгының Яңа Чишмә районы буенча бүлеге, Яңа Чишмә ав., Совет ур., 58, тел.: 2-26-73.» сүзләренә алмаштырырга.

3. Әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль**
**районы Башлыгы** **В.М. Козлов**